**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ**
**КАРАРЫ**

**№ 4** **26.10.2022**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль
Районы Үрсай авыл җирлеге составына керүче
Мөслим авылында 2023 елда гражданнарның
үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Мөслим авылында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2023 елда Урсай авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм анда катнашучыларның, Беек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, махсус хәрби операциягә җибәрелгән мобилизацияләнүчеләрнең гаилә әгъзаларыннан тыш, бер тапкыр бирелә торган түләүне киметергә 2 теркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә билгеләп, үзара салым кертергә һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

- Мөслим авылы урамнарын яктырту (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җиһазлар, урамнарны яктырту ремонтлау һәм хезмәт күрсәтү);
- Мөслим авылы территориясен төзекләндерүне оештыру (тракторчыга механикалаштырылган кар чистарту хезмәтләре өчен түләү, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәте);
- Мөслим авылында халыкны су белән тәэмин итүне оештыру (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту, шартнамә буенча эшләр өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру, су чыганакларының ЙСО белән тәэмин итү, ЗСО проектларын әзерләү буенча хезмәтләр өчен түләү, эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ ясау) ;
- Мөслим авылында бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү ("Халыкара елкәннәр көне» нә бүләк һәм сувенир продукциясе сатып алу, сәхнә костюмнары сатып алу);
- җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (үләнне механикалаштырылган чабу буенча хезмәтләр өчен түләү, килешү буенча эшләр өчен түләү, территорияне санитар чистарту буенча хезмәтләр күрсәтү, яшелләндерү чаралары, Мафлар сатып алу);
- Мөслим авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту: (Гафури урамы, 3 нче йорттан 27 нче йортка кадәр, Такташ урамы, 11 нче йорттан 89 нчы йортка кадәр юлларны профильләштерү, Такташ урамы, 1 нче йорттан 11 нче йортка кадәр вак таш җәю, таш салу, контракт буенча эшләр өчен түләү).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Урсай авылы, Үзәк урамы, 60 йорт.
-Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Мөслим авылы, Гафури урамы, 31 йорт;

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үрсай авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Урсай авыл җирлеге Башлыгы З.Х.Рахимьянова